СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

24.10.2018 пос. Октябрьский 50-218

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 маендагы 41-180 номерлы “Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге башлыгын ай саен бүләкләү турында” карарының үз көчен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында" 2018 елның 17 мартындагы 940 номерлы карары,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында" 28.03.2018 №182 карары, Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. «Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге башлыгына айлык премия турында» Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 маендагы 41-180 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карар 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш.Р. Азизов